| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГОРОД БОЛГАР» СПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«БОЛГАР ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» августа 2026 ел Болгар ш. № 5

2034 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре"
муниципаль берәмлеген җылылык белән
тәэмин итү схемасын раслау турында
(2026 елга актуальләштерү)

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законның (2014 елның 21 июлендәге редакциясе) 6 статьясының 1 пунктындагы 6 пунктчасы, «Җылылык белән тәэмин итү схемаларына таләпләр, аларны эшләү һәм раслау тәртибе турында» РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 22 февралендәге 154 номерлы карары нигезендә, гавами тыңлаулар бәяләмәсен исәпкә алып
карар бирәм:

1. 2034 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын (2026 елга актуальләштерү) кушымта нигезендә расларга.
2. Спас муниципаль районы Башлыгының «2034 елга кадәр чорга (2025 елга актуальләштерү) Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеген җылылык белән тәэмин итү схемасын раслау турында» 2025 елның 23 сентябрендәге 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) интернет челтәрендә халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе А. В. Костинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
"Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Л.Исланов